КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 май г.Казань № 374

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 29 гыйнвар, 36 нчы карары белән расланган Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 29 гыйнвар, 36 нчы карары белән расланган Инновацион эшчәнлек турында килешү төзү һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар резидентлары реестрына кертү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сервис – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын булдыру турында» 2020 ел, 2 ноябрь, 986 нчы карары нигезендә электрон исәпләү машиналары, мәгълүматлар базасы (базалары) һәм интеллектуаль эшчәнлекнең башка нәтиҗәләре өчен программалар рәвешендә эшләнгән, заявка бирүчеләрнең электрон төрдә заявка бирү хокукларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән мәгълүмат системасы.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Заявка «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә Югары технологияләр өлкәсендәге технопаркның рәсми сайты яисә Сервисның http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча урнашкан рәсми сайты яисә Сервисның мобиль кушымтасы аша электрон рәвештә бирелә.

Заявка бирү өчен заявка бирүче gosuslugi.ru сайтында (Россия Федерациясенең дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталы), Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (ЕСИА) расланган исәпкә алу язмасыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра һәм шәхси кабинетта бу Тәртипнең 4.1 пунктында билгеләнгән документларны электрон рәвештә урнаштыра.

Заявка, Сервистан файдаланып, электрон рәвештә бирелә һәм заявка бирүченең гади электрон имзасы белән имзалана. Гади электрон имзаны куллану тәртибе заявка бирүчеләрнең Сервиста Югары технологияләр өлкәсендәге технопарк урнаштырган оферта шартларын кабул итүе юлы белән төзелә торган гади электрон имза куллану турындагы килешүдә билгеләнә.»;

5.10 пунктта:

«а» пунктчасында «г» пунктчасында» сүзләрен «в» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «г» пунктчасында» сүзләрен «в» пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «а» – «г» пунктчаларында» сүзләрен «а» – «в» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

5.11 пунктта «бишенче абзацында» сүзләрен «дүртенче абзацында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаның 1 бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Килешү предметы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин